ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2015 Казан ш. № 4-1/г

***Татарстан Республикасы халкы тарафыннан кулланылу өчен җибәрелә торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында***

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 сентябрендәге утырышында хупланган 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү Фаразына, «Татарстан Республикасы халкы тарафыннан кулланылу өчен җибәрелә торган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2011 елның 27 октябрендәге № 252-э/2 санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы халкы тарафыннан кулланылу өчен җибәрелә торган табигый газга ваклап сату бәясен, өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алып, 5,16 сум/куб.м күләмендә билгеләргә.

2. 2015 елның 1 июленнән «Татарстан Республикасы халкы тарафыннан кулланылу өчен җибәрелә торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 11 апрелендәге 4-1/г санлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов